Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Түбән Мактама бистә башкарма комитеты

КАРАР

№ 6 27 апрель 2020 ел

Җир кишәрлегеннән һәм капиталь
төзелеш объектыннан шартлы
рәвештә рөхсәт ителгән төренә
рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясындагы 11 өлеше нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 14 статьясындагы 11 пунктына, 2020 елның 22 гыйнварындагы 2 нче гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә нигезендә,

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, «Түбән Мактама ш.т.б» МБ, Түбән Мактама ш.т.б, Промышленная ур., 7 В адресы буенча урнашкан 16:45:070104:458 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата «Дини куллану» № 3.7 коды- җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән «Конфессиональ объектлар» төренә рөхсәт бирергә
2. Әлеге карарны Түбән Мактама бистә башкарма комитетына «Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына (Корнилова А.О.) җир кадастр документациясенә тиешле үзгәрешләр кертү өчен җибәрергә.
3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Мактама бистә
башкарма комитеты җитәкчесе Г.Р. Нафикова